**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“28” ноябрь 2024 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлыТатарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылы территориясендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү).
- Авыл территориясен төзекләндерү (территорияне төзекләндерү (балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, үләннәрне чабу, агачларны кисү, чистарту,хезмәтләр өчен түләү).
- Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И.